Нурмөхәммәтова Р.С., ТДГПУ,
филология фәннәре кандидаты, доцент

# ТӘРҖЕМӘГӘ ӨЙРӘТҮ КҮНЕГҮЛӘРЕ

Тәрҗемә курсының эчтәлегенә кирәкле профессиональ белемнәр турында мәгълүмат бирү дә, тәрҗемә күнекмәләрен һәм осталыгын үстерү дә керә. Тәрҗемә күнекмәләрен һәм осталыгын үстерү тәрҗемә курсының төп максатын тәшкил итә, чөнки алар тәрҗемәченең практик һөнәри эшчәнлегенә турыдан-туры булыша, аны тәэмин итә. Осталык һәм күнекмәләр махсус сайлап алынган уку материалын куллану нигезендә барлыкка килә. Мондый материалларга тәрҗемә күнегүләре һәм уку текстлары керә.

Күнегүләр – тиешле осталыклар булдыруда төп ысул. Тәрҗемә осталыгы бәйләнешле текстлар тәрҗемә иткәндә дә үстерелә ала. Әмма теләсә кайсы текстны тәрҗемә итү бер төркем тәрҗемә бурычларын чишү белән бәйле була һәм кайсы да булса тәрҗемә проблемасы өстенлек иткән (күп булган) яки еш очраган текст табу шактый кыен. Махсус сайлап алынган күнегүләр укучыларның игътибарын аерым тәрҗемә проблемасына тупларга мөмкинлек бирә. Күнегүләр белән эшләү тәрҗемәгә өйрәтү курсының шактый өлешен алып тора. Бу вакытта тәрҗемә кыенлыкларын хәл итү ысуллары үзләштерелә, тәрҗемәнең техник алымнары эшкәртелә, тәрҗемә осталыгы үстерелә һәм тәрҗемә күнекмәләрен камилләштерү өчен нигез салына.

Башкарыла торган сөйләм гамәлләренең характерына карап, *тәрҗемә алды* (предпереводческий) һәм *тәрҗемә* (собственно переводческий) күнегүләре була. *Тәрҗемә алды күнегүләре*нең максаты – уңышлы тәрҗемә өчен шартлар тудыру, аралашуга тиешле юнәлеш бирү, студентларның тел һәм фон белемнәрен тикшерү, аларга тәҗрибәле, югары квалификацияле тәрҗемәчеләрнең типик тәрҗемә бурычларын ничек хәл итүләрен күрсәтү. Бу тип күнегүләрнең иң әһәмиятләреннән берсе – чыганак һәм тәрҗемә телләрендәге параллель текстларны чагыштыру, аларның аермасын күрсәтү, басылып чыккан тәрҗемәләрне оригинал белән чагыштыру; тәрҗемәче

кулланган метод һәм алымнарны тәнкыйть күзлегеннән анализлау, текстны аңлау тирәнлеген һәм фон белемнәрен тикшерүне күздә тоткан сорауларга җавап бирү, текст эчтәлегенең нигезендә яткан концепцияләрне тикшерү, аңа бәйле терминнарны һәм төшенчәләрне барлау, тәрҗемә теленнән белемнәр үзләштерүне камилләштерүгә караган күнегүләргә караган күнегүләр эшләү (синонимик рәтләр төзү, синонимнарның мәгънә төсмерләрен аеру, вариантларга стилистик бәя бирү, хәбәрләрне үзгәртү, бирелгән темага чыгыш ясау һ.б.).

Һәр күнегү билгеле бер бурычны хәл итүгә юнәлтелә, ул, тибына карап, биремдә формалаштырыла. Әмма күп кенә очракларда биремнәр төп бурыч белән беррәттән, тулы бер төркем өстәмә бурычларны чишүне дә таләп итә.

Кагыйдә буларак, күнегүләр билгеле бер тәрҗемә кыенлыгын үз эченә алган 15-20 җөмләдән гыйбарәт була. Алар төрле текстлардан сайлап алына, чөнки тиешле проблема җитәрлек күләмдә булган тоташ текст табу шактый кыен. Мондый күнегүләр өчен материал рәвешендә тел чараларын куллануда индивидуаль-автор үзенчәлекләре булмаган текст алынырга тиеш. Контексттан өзеп алынган хәбәрләмәләрне куллану аларны аңлауда һәм тәрҗемә итүдә кыенлыклар тудыра. Бу кыенлыкларны өч төрле юл белән хәл итеп була:

1) тәмамланган, шәрехләү өчен зур контекст таләп итми торган җөмләләр сайлап алына. Кирәк очракта аерым җөмләне, эчтәлеген ачыклап, табигыйлыгын бозмыйча, бераз үзгәртергә мөмкин;

2) өстәмә мәгълүматны укытучы үзе хәбәр итәргә әзер булырга тиеш;

3) аңлауны һәм тәрҗемә вариантларын тикшерү.

Күнегүләр башкарганда укытучының комментарийлары әһәмиятле роль уйный. Хәбәрләмә контекстын тулыландырудан тыш, укытучы студентларга кирәкле фактик материалларны җиткерә, таныш булмаган реалияләрне аңлата, тел хаталарын төзәтә, анализлауда дөрес юлны күрсәтә һәм мөмкин булган тәрҗемә вариантларын сайлаша. Өйрәнелгән белемнәрне, алымнарны искә төшереп тору да мөһим.

Күнегүнең характерына карап, ул дәрестә эшләнергә дә, өй эше итеп бирелергә дә мөмкин.

Тәрҗемә күнегүләренең түбәндәге төрләре була:

1) оригинал һәм тәрҗемә телләре берәмлекләренең, төзелмәләренең үзенчәлекләре белән бәйле тәрҗемә бурычларын хәл итү осталыгын үстерә торган *тел күнегүләре.* Бу күнегүләрдәге биремнәрдә тәрҗемәдә аерым игътибар ителергә тиешле тел берәмлеге яки төзелмә күрсәтелә. Мондый күнегүләрдә студентның бурычы аерым тел берәмлекләрен тәрҗемә итү дә, хәбәрләмә составында бирелгән берәмлекләрнең һәм төзелмәләрнең мәгънәләрен күчерү, билгеле бер берәмлек-төзелмәләр булган хәбәрләмәләрне тәрҗемә итү дә булырга мөмкин.

Тел күнегүләре тәрҗемә телендә билгеле бер типтагы тел берәмлекләренең семантикасына һәм кулланыш үзенчәлекләренә бәйле кыенлыкларны хәл итү осталыгын үстерүне максат итеп куя. Аларны әлеге берәмлекләрнең характерыннан чыгып, *лексик, фразеологик, грамматик* һәм *стилистик* күнегүләр дигән төрләргә бүлү уңайлы.

Чыганак телдә ирекле һәм тотрыклы сүзтезмәләрне куллану үзенчәлегенә бәйле кыенлыкларны хәл итү күнегүләре *лексик* күнегүләр арасында аерым төркем тәшкил итә. Бу төр күнегүләр сүзтезмәләрне аерып алып тәрҗемә итүгә дә, хәбәрләмә яки текст өземтәсе составында тәрҗемә итүгә дә багышлана ала.

Тәрҗемәдәге *грамматик* проблемалар чыганак телнең тәрҗемә телендә тәңгәллеге булган формаларга һәм төзелмәләргә дә, шулай ук эквивалентсыз форма-төзелмәләргә дә карый. Димәк күнегүләрдә алар барысы да исәпкә алынырга тиеш. Модаль формаларның мәгънәләрен тәрҗемә итүгә аерым игътибар бирү мөһим.

*Стилистика* өлкәсенә караган күнегүләр оригиналдагы стилистик тамгаланган, аерымланган сүзләрнең мәгънәләрен күчерүгә юнәлтелергә тиеш. Шулай ук вакытта төрле стилистик алымнарга (чагыштыру, метафора, сүз уйнату һ.б.) һәм синтаксик сурәтләү чараларына тәңгәллекләр эзләү

күнегүләре дә үткәрелсә яхшы. Монда стандарт стиль чараларын тәрҗемә итүгә дә һәм индивидуаль-автор үзенчәлекләрен күчерүгә дә аерым игътибар бирелә. Тәрҗемәдә стилистик проблемаларны хәл итү оригиналның стилистик нюансларын төгәл һәм тулысынча күчереп булмауга бәйле югалтуларны компенсацияләүнең төрле юлларын иҗади файдалану осталыгын күздә тота;

2) төрле тәрҗемә ысулларын һәм алымнарын куллану осталыгын эшкәртә торган *операцион күнегүләр.* Алар тәрҗемәдә билгеле бер алымны куллану, аны сайлауны дәлилләү, бу алымны куллану ысулын аңлатуны күздә тота. Мондый күнегүләрне дүрт төркемгә бүлеп карарга була:

- беренче төркем күнегүләр тәрҗемәдә кулланылган метод һәм алымнарны тануга юнәлтелә. Моның өчен студентларга тәрҗемә хәбәрләмәләрен чыганак белән чагыштырып, һәр очракта нинди стандарт методлар кулланылуын билгеләргә кушыла. Әлеге күнегүләргә кергән хәбәрләмәләр бер ысул белән генә яки төрле ысуллар кулланып тәрҗемә ителгән булырга мөмкин. Бирелгән мисаллар үрнәк булу шарт түгел, әмма студентларга таныш алым кулланылуы ачык күренеп тору мөһим. Әгәр басылып чыккан тәрҗемәдән алынса, бигрәк тә отышлы;

- икенче төркем күнегүләрне башкарганда кулланылган тәрҗемә алымын тану гына түгел, аның уңышлымы-юкмы икәнен бәяләү дә таләп ителә. Мондый күнегүләрнең ике төре бар. Беренче очракта оригинал да, тәрҗемә дә бирелә һәм тәрҗемә алымын сайлауның дөреслеге бәяләнә. Икенче очракта студентлар бары тик оригинал белән генә эш итә һәм күрсәтелгән алымны куллану мөмкинлеген бәяли;

- өченче төркем операцион күнегүләрне башкарганда, тәрҗемәдә башка алымнар куллану мөмкин булса да, билгеле бер алымны куллану бурычы йөкләнә. Бу очракта тәрҗемә ителәсе материалдагы хәбәрләмәләр нәкъ менә күрсәтелгән алымны куллануны таләп итәргә тиеш;

- дүртенче төркем күнегүләр конкрет хәбәрләмәне тәрҗемә итү өчен иң уңышлы алымны сайлау күнекмәләрен үстерү һәм куллануга юнәлтелә.

Мондый күнегүләрне эшләгәндә студентлар кулланыласы алымны мөстәкыйль рәвештә билгелиләр;

3) тәрҗемә процессының төрле этапларында тиешле эш-гамәлләрне уңышлы башкару күнекмәләрен барлыкка китерә торган *коммуникатив күнегүләр*. Болар тел берәмлекләренең контекстуаль мәгънәләрен ачыклау, хәбәрләмәнең мәгънәсен шәрехләү, тәрҗемә тәңгәллекләре сайлау, төрле авырлыктагы хәбәрләмәләр һәм текстлардан өзекләр тәрҗемә иткәндә тәрҗемә бурычларын комплекслы чишү кебек биремнәрне үз эченә ала. Башкача әйткәндә, мондый күнегүләр тулаем тәрҗемә процессының аерым этапларын башкару осталыгын үстерәләр. Мөстәкыйль сөйләм гамәлләре таләп итә торган күнегүләрне дә берничә типка аерып карыйлар:

- беренче тип күнегүләр студентларның чыганак һәм тәрҗемә телләрендәге төрле дәрәҗә берәмлекләр белән төрлечә эшләүне таләп итәләр. Мәсәлән, *сүз* дәрәҗәсендә түбәндәге биремнәрне үтәү максаты куелырга мөмкин: синонимик рәттәге сүзләрнең аермаларын аңлатырга; чыганак һәм тәрҗемә телләрендә параллель синонимик рәтләр төзергә һ.б. *Сүзтезмә* дәрәҗәсендә: чыганак телдә бирелгән сүзләрдән мөмкин булган сүзтезмәләр төзергә һәм тәрҗемә телендә аларның эквивалентлары бергә килә алу-алмау дәрәҗәсен күзәтергә; ике телдә мәгънәләре бердәй, әмма составлары белән аерыла торган сүзтезмәләр төзергә; тәрҗемә телендә эквиваленты булмаган тотрыклы сүзтезмәләр исемлеген булдырырга һ.б. *Грамматика* дәрәҗәсендә: бердәй грамматик категорияләрне (вакыт, заман һ.б.) белдерү ысулларын чагыштырырга һ.б.;

- икенче төркем күнегүләр бирелгән текстлардагы тәрҗемә кыенлыкларын тануны һәм аларны тикшерүне күздә тота. Фикер алышу өчен гомуми проблемалар да, хосусый проблемалар да чыгарылырга мөмкин. Бер яктан, оригинал текстының максатын, тибын һәм шуларга бәйле тәрҗемә стратегиясе үзенчәлекләрен бәяләү бурычы куела ала. Икенче яктан, чыганак текстта булган үзенчәлекле лексик, грамматик һәм стилистик күренешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән аерым проблемалар турында фикер алышу

тәкъдим ителә. Мондый күнегүләрнең гомуми максаты – текстка тәрҗемә алды анализы ясау күнекмәләрен үстерү;

- өченче төркем күнегүләр оригинал һәм тәрҗемә текстлары белән төрлечә эш итүне үз эченә ала. Боларга оригинал эчтәлегенең планын төзү, авторның әйтергә теләгән төп фикерен формалаштыру, текстның эчтәлеген сөйләү һ.б. керә. Тәрҗемә текстларына килгәндә исә, ул оригинал белән бергә дә, үзе генә дә бирелергә мөмкин. Бу вакытта түбәндәге эш төрләрен тәкъдим итәргә була: текстны башкача сөйләп бирү, нормалардагы һәм узустагы хилафлыкларны төзәтү, текстны оригиналга якынайту, күздә тотылган мәгънәне әйтеп бирү һ.б.;

- тәрҗемәгә куелган максатлар һәм күздә тотылган рецептор тибына бәйле рәвештә бер үк текстны төрле ысуллар белән тәрҗемә итү күнегүләре дүртенче төркемне тәшкил итә. Максат сыйфатында тәрҗемә басылачак газета яки журналның характеры, тәрҗемәнең реклама, сәяси һәм пропаганда максатында кулланылу ихтималы күрсәтелергә мөмкин. Биремдә төрле яшьтәгеләр өчен, теге яки бу өлкәдә профессионаллар яки профессионал булмаганнар өчен дигән тамгалар да була ала.

Инде әйтеп үтелгәнчә, тәрҗемә курсының бурычы - махсус белем һәм осталык нигезендә автомат яки ярымавтомат тәрҗемә күнекмәләре үстерү. Шунлыктан тәрҗемә күнегүләре системасы дәрес вакытында төрле авырлыктагы һәм төрле күләмдәге текстларны даими рәвештә тәрҗемә итү белән тулыландырыла.

**Кулланылган әдәбият**

Алексеева И.С. Профессиональный тренинг переводчика: Учебное пособие по устному и письменному переводу для переводчиков и преподавателей. – СПб: Изд-во “Союз”, 2003.

Комиссаров В.Н. Современное переводоведение. – М.: ЭТС, 2002.

Латышев Л.К. Технология перевода. - М.: Издат.цент “Академия”, 2005.

Сибәгатов Р.Г. Тәрҗемә методикасының нигезләре. – Уфа, 1979.

Федоров А.В. Основы общей теории перевода. – М.: ООО “Издательский дом “ФИЛОЛОГИЯ ТРИ”; СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2002.

Юсупов Р.А. Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005.